## «Георгий тасмасы - буыннар символы» мастер-класс

Җиңү көне алдыннан Балтач үзәк китапханәсе хезмәткәрләре Балтач гимназиясе укучылары өчен «Георгий тасмасы - буыннар символы» дигән мастер-класс оештырдылар. Әмма иң мөһиме аны ясау үзе түгел, ә символ турында сөйләшү булды. Китапханәчеләр укучыларга Георгий тасмасы нәрсә икәнен, ни өчен ул үзендә кара һәм кызгылт сары төсләрне берләштерүен, нинди бөек тарихка иябулуын һәм ни өчен бүген аны хөрмәт белән киеп йөрү буыннар бәйләнеше билгесе. Бөек Җиңү турында онытмау-бу хәтерне киләчәктә дә тапшыру дигән сүз.






